**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                    КАРАР

______________                                    __________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының хәрби комиссариатында хәрби-табиб комиссиясе эшен оештыру турында

«Хәрби комиссариатлар турында Нигезләмәне раслау турында» 2012 елның 7 декабрендәге 1609 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Хәрби-табиб экспертизасы турында Нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 4 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә, контракт буенча хәрби хезмәткә керергә теләк белдергән, уку-укыту үзәкләрендә хәрби әзерлек узарга теләк белдергән, белем бирү оешмаларын тәмамлаган, белем бирү оешмалары каршындагы Хәрби кафедраларда (хәрби уку факультетларында) хәрби әзерлек узган һәм белем бирү оешмаларын тәмамлаган гражданнарга карата хәрби-табиб экспертизасы мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү максатыннан, һәм хәрби җыеннарга чакырганда, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең мобилизацион кешеләр резервына керүче һәм анда булган гражданнарны исәпкә алу максатыннан, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Запастагы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керә торган гражданнарның яраклылыгы турында, хәрби җыеннарга чакырылучылар, Россия Федерациясе Кораллы көчләре запасында булган, училищеларга һәм хәрби-уку йортларына керүче гражданнар, хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмә нигезендә бәяләмә чыгару хокукы белән хәрби-табиб комиссиясен төзергә.

2. Актаныш районы хәрби комиссарының 2022 елның 07 ноябрендәге 74 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы хәрби-табиб комиссиясенең төп һәм резерв составын расларга.

3. Актаныш муниципаль районының запаста торучы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керә торган гражданнарын медицина тикшерүе уздыру өчен Актаныш муниципаль районының үзәк хастаханәсен (килешү буенча) җәлеп итәргә.

4. Гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны уздыру чорында «2023 елда 1996-2005 елларда туган гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны уздырганда Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең эш планы» белән расланган составта күрсәтелгән гражданнарны медицина тикшерүен уздыру өчен кирәкле табиб-белгечләрне бүлеп бирергә.

5. Актаныш район үзәк хастаханәсенең баш табибына тәкъдим итәргә:

-1998 елгы 53-ФЗ номерлы "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында РФ Законы нигезендә табиб-белгечләр һәм урта медицина персоналын бүлеп бирергә";

- медицина комиссиясе эшендә катнашканнарны, медицина тикшерүен уздыру чорына төп эш урыны буенча хезмәт хакын саклап калып, төп эштән азат итәргә;

- табиб-белгечләр булмаганда, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы белән аларны башка медицина учреждениеләреннән бүлеп бирүне килештерергә;

-Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 04 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә, медицина комиссиясен кирәкле медик-санитар мөлкәт белән тәэмин итәргә;

- медицина тикшерүе узу чорында югарыда күрсәтелгән гражданнарга нәтиҗәне кулга бирү белән кирәкле тикшеренүләрне оештырырга һәм уздырырга;

- стационар тикшерү өчен Актаныш район үзәк хастаханәсенә 2 койка-урын бүлеп бирергә, бу максат өчен иң җаваплы табиб-белгечләрне беркетергә һәм тулы һәм сыйфатлы тикшерүне тәэмин итәргә;

-дәвалау-профилактика учреждениеләре гаебе белән гражданнарны тикшерүне нигезсез озакка сузу очраклары турында кичекмәстән хәбәр итәргә һәм аны тәмамлау өчен конкрет чаралар күрергә.

6. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Запаста торучы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керүче гражданнарны медицина тикшерүе уздыру өчен штаттан тыш даими эшләүче хәрби-табиб комиссиясен төзү турында» 2022 елның 12 гыйнварындагы ПР-4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш районы хәрби комиссарына килештерү буенча йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов